**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

2024 елның 11 июне 47-РС номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023елның 08 декабрендәге 119-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 8 ноябрендәге 119-РС номерлы карары (2024 елның 8 апрелендәге 26-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 39 бүлекнең 4 өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне беренче тапкыр алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Т. Гарифуллинга йөкләргә.

**Глава - Председатель Совета**
**муниципального района** **И.Ф. Зарипов**